**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советы Карары**

**“31” июль 2019 ел** **№ 125**

**2017 елның 14 ноябрендәге “Җир салымы турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советының 69 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советының 2017 елның 14 ноябрендәге “Җир салымы турында”гы 69 номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 маддәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы “Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы Федераль законда каралган гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата 0,23%;”.

2. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көненнән бер ай узгач, әмма 2020 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түгел срокта үз көченә керә.

3. Әлеге Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, Октябрь урамы, 65 йорт ( авыл җирлеге хакимияте бинасы);

- ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, 2 нче Октябрь урамы, 50 нче йорт (мәдәният йорты бинасы),

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының Рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге Карар рәсми рәвештә халыкка хәбәр ителгән (басылып чыккан) көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Башлыгы, Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советы рәисе** **И. А. Зиновьев**